Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге
Олы Дүртөйле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

12 октябрь, 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең Олы Дүртөйле торак пунктында 2024 елның 12 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 53 (илле өч).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 41 (кырык бер).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 40 (кырык).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 1 (бер).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше белән түбәндәге сорау буенча гражданнар җыенының карары нигезендә «Сез, 2025 елда Олы Дүртөйле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарны, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга**.

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В. Поповская